ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш,
423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбенең структур бүлекчәсе «Мәсәде башлангыч мәктәбе» мәгариф учреждениесен бетерү турында

Мәгариф системасында оптимальләштерелгән чаралар белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы бюджетының чыгым өлешен экономияләү максатларында, Актаныш муниципаль районы мәгариф оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында 2018 елның 10 августындагы карарын кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә, Мәсәде авыл җирлеге халкы җыенының 2018 елның 1 августындагы фикерен исәпкә алып, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең структур бүлекчәсе «Мәсәде башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесен бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры А.С.Хаҗиевка 2018 елның 01 сентябренә кадәр:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына үзгәреш проектын әзерләргә; Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбенең структур бүлекчәсе «Мәсәде башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесен закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә бетерергә. -

3. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына ТР Актаныш муниципаль районы Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбенең структур бүлекчәсе «Мәсәде башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесенең мөлкәтен "Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе"нә тапшыру өчен кирәкле документлар әзерләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф. Нурлыевага йөкләргә.

Башкарма комитет вазифаларын башкаручы Л.Р. Сираева